| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
|---|---|
| Аксубай муниципаль районы **муниципаль беремлеге** | **Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование** |
| 423072 Иске Тимошка Авылы Ленина урамы, 2` | 423072 с.Старое Тимошкино улица Ленина, 27 |
| тел. 884344 4-53-40 | тел. 884344 4-53-40 |

ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2021 ел, 18 ноябрь № 4

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче
Батыр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы Татарстан», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019 , № 99 карары нигезендә,

2021 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Батыр авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Батыр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу (ЩПС), грунт һәм вак ташны күтәрү, чәчү һәм тигезләү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)»

« РИЗА» «КАРШЫ» «Тыелып калды».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 21 граждан кертелгән.

Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны: 14

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 14 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

«Тыелып калды» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Батыр авылы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

2. Мәсьәлә буенча карарны таныргa: «2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Батыр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу (ЩПС), грунт һәм вак ташны күтәрү, чәчү һәм тигезләү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)»

3. Әлеге карарны Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының http://aksubaevo.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче: П.А.Мулеева